Рөстәм Мингалим

Галстуклы кәҗә

a
a

Рөстәм Мингалим

Галстуклы кәҗә

ШИГЫРЬЛӘР

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1992

ББК 84(2Тат)-5
М 50

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРГА

Рәссамы С. ИБРАҺИМОВА

Мингалимов Р.

М 50 Галстуклы кәҗә: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр. 1992 — 32 бит.
ISBN 5—298—01027—X

М $\frac{4803560202-105}{М\ 132(03)-92}$ 126—92

Мингалимов Рустем Галиевич

КОЗА В ГАЛСТУКЕ

Стихи

(на татарском языке)

ИБ № 6220

Мөхәррире *Б. Рәхимова.* Бизәлеш мөхәррире *Ф. Хәсьянова.* Техник бизәлеше *Ф. Габдрахманова.* Корректоры *Х. Фәйзрахманова.*

Җыярга тапшырылды 16.10.91. Басарга кул куелды 31.03.92. Форматы 60×90 1/16. Офсет кәгазе № 1. Гарнитурасы «Литературная». Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 5,0. Нәшер-хисап табагы 1,25. Тиражы 20 000 экз. Заказ К-412. «С-1».

© Татарстан китап нәшрияты, 1992

НИЧӘ ҚАБАТ ЧИРТТЕ?

(Мәсьәлә)

Бер кат әйтте әти —
ишетмәдем.
Икенче кат әйтте —
ишетмәдем.
Өченче кат әйтте —
ишетмәдем.
Аннан ул башыма
Шундый әйбәт чиртте,
Искә төште, әти,
ишеткәнмен!
Ишеткәнмен!
Ишеткәнмен!

ҚАЯ ҚИТҚӘН

Минем әти кайтмый бит,
Кая киткән, ник киткән?
Бик сагындым аны мин,
Ул сагынмый да микән?
Инде хәйлә таптым мин
Әтиемне күрергә:
Күзем ачсам — әти юк,
Күзем йомсам — күренә.

УКЫЙ БЕЛӘ ӘТИ ДӘ

А хәрефен тиз таныйм,
Тагын күп хәреф таныйм.
Ничә хәреф таныймы?
Анысын әти саный...

Укый белә әти дә,
укый белә әни дә.
Укы да укы гына —
Китап күп безнең өйдә.

...Хәзер инде укырга
Мин дә өйрәнеп киләм.
Инде бөтен китапның
Рәсемен укый беләм.



ҖИДЕ ЧЕБЕШ

Җиде чебеш: «Пи-пи!»— ди,
Бодай сиптем аларга.
Җиде чебеш: «Пи-пи!»— ди,
Тары сиптем аларга.

Алар һаман: «Пи-пи!»— ди,
Димәк, алар: «ипи!» — ди.

Алып килдем ипи дә...
Ашыйк бергә, пипиләр!

◎

ҖИЛ АЯГЫН КҮРМӘДЕМ

Йөгереп килде дияр идем,
Җил аягын күрмәдем.
Очып килде дияр идем,
Җил канатын күрмәдем.
Юып кына элгән идем —
  Җилләп кибә керләрем!

ЭНЕМ БАР

Шатлыгым бар — өем бар,
Әнием-әтием бар.
Минем гармуным да бар,
Гармун хәтле энем бар.
Энем мине ярата,
Мине күрсә — гел көлә.
Еласамы?!
Еласа ул —
Сызып кына җибәрә
  Гармун тавышы белән.

СӨЙЛӘШӘ ДӘ БЕЛМИ УЛ

И, Гөлгенә, Гөлгенә —
Кечкенә дә бер генә!
Сөйләшә дә белми ул,
Аңлаша гөр-гөр генә.
Гү-гү генә, Гөлгенә,
Ул җаен табып ала:
Ачыкканын әйтергә —
Бармагын кабып ала.
Үсә аның бармагы,
Үсми калсын кай ягы?
Инде үрти белә ул —
Тел күрсәтә дөньяга.
Менә шулай, янәсе —
Дөнья иске,
ул яңа!

ӘЛЕ ҖӘЙ БЕЗНЕҢ ЯКТА

Кышны да бик яратам,
Язны да бик яратам.
Әле җәй безнең якта,
Матур,
    әй,
        безнең якта!
Көндез җир чәчәк ата,
Төнлә күк чәчәк ата.
Күк тә мине ярата,
Җир дә мине ярата.
...Әти дә мине ярата
Һәм әнине ярата.

ҖЫЛЫ ЯҢГЫР, ДАМИР ҺӘМ ГӨЛНАЗ

Җылы яңгыр явып тора,
Якты суы агып тора...
Ә мин таеп егылдым да
Пычыранды чалбарым.
Гөлназ юып бирә иде,
Юам, Дамир, дигән иде,
Чалбарымны салмадым.

АБЫЕМ БЕЛӘН АПАМА

Нидер эшли башласам,
«Шакылдама!» — дидегез.
Нидер сөйли башласам,
«Такылдама!» — дидегез.
Алай яшәп булмый шул,
Алай яшәп булса ул:
Үзегез дә —
шакылдамас,
такылдамас идегез.

КҮРЕГЕЗ!

Күрегез, әй, яшел ярга
Килеп кунды җиде карга!
Башта кунды кызыл карга,
Аннан кунды сары карга,
Аннан кунды —
яшел карга...
— Каян килсен яшел карга?!
— Булмас ла ул кызыл карга!
Шулай шаулап бөтен авыл —
Чапты карга карарга...
...Тик өлгермәделәр генә
Каргаларны күрергә:
Алар килеп җиткәнче
Җиде карга әйләнде
Салават күперенә.

ХАТАЛЫ ШИГЫРЬ

(Мәсьәлә)

Яуды, яуды, яугыр яуды —
Атна буе коеп торды.
Бу яугырлы көннәр мине
Бик туйдырды, боектырды.
Яумагырлы көннәр килсә,
Мин балыкка йөрер идем.
...Бу шигырьдә ничә хата?
Үзем әйтеп бирер идем —
Белмим шул.
Ә
кем
белә?

ИҢ ЗУР КЕШЕ

Күпне белгән кеше —
Ул зур кеше була...
Күптән-күптән белгән —
Бик зур кеше була.
Бик зур кешегә дә
Тиң зур кеше була.
Әти-әнидән дә
Зуррак кеше
булмый:
Шуны белгән кеше —
Иң зур кеше була!



САМОЛЕТ

Кызу барган уңайга,
Очып китте трамвай,
Оча-оча трамвай...
Әй,
    трамвай дип инде
Ялгыш кына әйтелде!
Оча-оча самолет,
оча безнең самолет!
Оча-оча биектә —
Кинәт туктадык күктә.

Күктә түгел икәнбез,
Җиргә төшеп җиткәнбез.

©

ШАЙТАН КИЛДЕ КУНАККА

Кичә шулай көнозын
Өйдә тордым берүзем.
Яныма кичке якта
Шайтан килде кунакка.
Ул инде, аһ,
ул инде —
Иң матур шайтан иде!

Ул — кочаклап үбәрлек,
Әкият итеп сөйләрлек!

Ә мин шулай иттем дә,
Кочаклап бер үптем дә,
Озатып та җибәрдем...
Шул шайтанны —
Шул әкиятне
Бүген сезгә сөйләдем.

ӘНКӘЙ, ӘТКӘЙ ҺӘМ МИН

Ишек ачып өйгә кергәч —
Мин шатланам.
Әнкәемне өйдә күргәч —
Бик шатланам.
Әткәем дә өйдә йөргәч —
Канатланам:
Ераклардан
очып кайткан
кебек булам!
Әткәемне кочып алам,
Әнкәемне үбеп алам!

ХА-ХА!

Озын-озын ике абый
Безгә күрше торалар:
Зур-зур күзлек кигәннәр,
Минем янга килгәннәр.
Көләләр дә көләләр,
Миңа, авызың зур, диләр.
Авызың тулы сүз, диләр.
Үзең бәләкәй, диләр.

Үскәнемне дә күрмиләр,
Үзләре — күзлекләләр,
ха-ха!

КҮРШЕЛӘР

Бүген миңа ни булган,
Күршеләр?
Кулларыма карагыз да
белегез!
Бүген миңа ни булган,
Күршеләр!
Күлмәгемә карагыз да
белегез!
Бүген миңа ни булган,
Күршеләр?
Күзләремә карагыз да
күрегез!
Күрмәсәгез,
белмәсәгез,
менә шул:
Туган көнем бәйрәменә
керегез!

КУНАК ҺӘМ БЕЗ
ЯКИ БЕР, ИКЕ, ӨЧ!

Өчәү бергә:
«Өч!» — дидек.
Өчәү бергә —
Йөгердек.

Артта калган —
Тай булыр!
Тайдан алда —
Ат булыр!
Атны узып йөгергән —
Мактанчык кунак булыр.
Аңа рөхсәт, мактансын,
Атны узып карасын!

Тайдан артка калмасын,
Бер, ике, өч!

ЛӘХМӘТ, ГӘХМӘТ
ҺӘМ РӘХМӘТ

«Р» диясе урында —
«Л» дигән балаларга
Кычкырып тора карга:
— Кар-кар-кар! — ди ул,—
«Р» хәрефе бар,— ди ул.

«Р» диясе урында —
«Г» дигән балаларга
Кычкырып йөри карга:
— Кар-кар-кар! — ди ул,—
«Р» хәрефе бар,— ди ул.

Бигрәк тырыш бу карга,
Ләхмәт инде аңарга.
Гәхмәт инде аңарга.
Рәхмәт
бездән
аңарга!

ГАЛСТУКЛЫ КӘҖӘ

Безнең кәҗә —
Кукшы кәҗә,
Туп-туп басып китә ул.
Матур китә, матур кайта,
Әнә кайтып җиткән ул.

Туп-туп басып,
Кайтып җиткән,
Карап торам таң калып:
Кара кастюм,
Ак якалы.
Галстугы — сакалы!

ОЧТЫ-КИТТЕ...

Әй, ак чәчәк!
Исемең ничек?
Калыйм әле белеп.
Ник син болай ялгыз үстең,
Юл буена килеп?

Очты-китте зур ак чәчәк,
Миңа канат болгап...
Ак чәчәк дип үрелгәнем —
Ак күбәләк булган!

КӨРӘК

Карлар көри юлдан,
Көри-көри көрәк:
Сыерга — юл кирәк,
Сарыкка — юл кирәк!
Песигә — юл кирәк,
Кешегә — юл кирәк!

Юлдан карлар көрәп,
Арып беткән көрәк.

Йоклап киткән көрәк,
Башын карга терәп.

Инде ул төш күрә,
Бер төш күрә көрәк:
Йөри
көрәк
карны
кабат юлга көрәп.
Сарык баткан юлда,
Сырты гына күренә.
Юлда баткан песи —
Борыны гына күренә.
Тездән карга баткан,
Сыер тора мөгрәп...
Начар төш бу, көрәк!
Уян тизрәк!

ЯЗ

Кышкы күктә болытлар
Толып киеп йөргәннәр.
Әйе, шулай йөргәннәр,
Язга шулай кергәннәр.

Толыпларын салырга
Онытканнар да алар:
Инде хәзер тирлиләр,
Тирлиләр дә
Эриләр,
Яңгыр булып явалар.

⊙



МАЙ КИЛГӘН

Май килгән!
Май килгән!
Май чәчәккә бай килгән.
Төне буе алмагач
Ак төш күреп сөенгән.
Ул бит актан киенгән,
Сөенече шуңадыр.
Чәчәкләре — алмага,
Алмалары — миңадыр.

ГӨРЛӘВЕККӘ ЮЛ АЧТЫК

Бишебездә — биш көрәк,
Юкка шулай йөрмәдек.
Гөрләвеккә юл ачтык,
Бик шатланды гөрләвек!

Бик шатланды биш көрәк!
Гөрләп киткән гөрләвек,
Биш көрәк тә
Биш малай —
Бергә-бергә гөрләдек!

КЕМДЕР

Кил, яңгыр, кил-кил,
Кемдер битен юмаган!
Ашаганда боткасын —
Борынына буяган!
Кил, яңгыр, кил-кил,
Безне өйгә куарсың!
Бит юмаган Кемдерне
Тотып битен юарсың!
Кил, яңгыр, кил-кил,
Шаулап-гөрләп
яварсың!

БӘЛӘКӘЙ КӨЙМӘ

Көймә үскәч пароход буламы?

Бала соравы

Чишмә агып —
Елга булган.
Елга туктап —
Күл булган.
Көймә китә
Күл буйлап.
Без калабыз кул болгап:
— Сау бул, сау бул, әй, көймә!
Сау бул, бәләкәй көймә!
Йөзә-йөзә үс кенә,
Үсә-үсә йөз генә...

Үсеп зур пароход бул да
Утыртырсың безне дә.

ЯШЕН

Яшен, яшен — яшь мәче,
Елгыр мәче, ут мәче!
Күктә тугач, шунда тор,
Безнең якка үтмә син.
...Нәрсәнедер җимерде,
Дөбер-шатыр китерде.
Күктә туган ут-мәче
Җиргә таба сикерде.

Безнең гаярь мәчеләр
Койрыкларын кыстылар.
Батыр-батыр малайлар
Тычкан булып постылар.

... Ярый әле ут-мәче
Безнең янга җитмәде:
Аны тотып хуҗасы
Оясына бикләде.

◎

ҚАРЛЫГАННАР КАРАЛГАН

Қарлыган, карлыган —
Бакчабызга таралган.
Қуаклары куаныша —
Қарлыганы каралган.

Қарлыган, карлыган —
Барысы да каралган.
Барысы да әзер тора
Учларыма тамарга.

Қарлыганнар каралган
Учларыма тамарга.

БӘХЕТЛЕ ҚЫЗ ӘНИСӘ

Аяклары ак кына,
Егылмады чак кына:
Атлап китте Әнисә, һай,
Тәпи китте Әнисә!
Бәхетле кыз — Әнисә!
Атлап бара сак кына,
Егылмас ул Әнисә:
Уң ягында әтисе, һай,
Сул ягында әнисе!
Бәхетле кыз — Әнисә!

ЯТИМ МАЛАЙ

Бер малайның әнкәсе дә юк икән,
Ул малайның әткәсе дә юк икән.
Ул елаган —
Беркем дә ишетмәгән.
Озак-озак елагач,
Йоклап киткән.
Малай тәмле алма күргән төшендә,
Тотып йөргән, ашаган ул беразын.
...Уянган да
Инде тып-тын утыра.
Ятим малай кемнән алма сорасын?

ЧИТ МӘЧЕ

«Мияу-мияу?!» — ди мәче,
Һаман өйгә кермәкче...

Ник туган бу чит мәче,
Ник ялгышкан шулай ук?
Шәһәр хәтле шәһәрдә —
Бер мәчегә урын юк.

Аны өйгә кертмиләр:
— Перес, перес!
Кит! — диләр.

ЙӘ, ӘЙТЕГЕЗ, БЕЛСӘГЕЗ?

(Мәсьәлә)

Су керергә чакырган
Ун тавыкны бер үрдәк.
Моны күргән ак әтәч,
Әйе, ак әтәч күргән.

Бер үрдәк тә ун тавык
Киткәннәр су керергә.
...Су буеннан авылга
Кайткан бары бер үрдәк.

Әтәч кереп Хуҗага,
Күргәннәрен сөйләгән.
Шул көннән соң авылда
Ул үрдәк күренмәгән.

Кая киткән ул үрдәк?
Тавыклар кая киткән?
Йә, әйтегез,
Белсәгез?
Ак әтәч — белә икән.

БАРЫП ЧЫКТЫМ ЧОКЫРГА

Бардым-бардым мин кырда,
Барып чыктым чокырга.
Бер атласаң батарсың,
Бер ел чыкмый ятарсың?!
Ә мин берне атладым —
Һәм чокырга батмадым.
Ике адым атладым —
Һәм чокырга батмадым.
Мин өч адым атладым
Һәм чокырга батмадым.
Мин! Мин!
Чөнки мин
          Артка таба атладым!

КЫЗЫК РӘСЕМ

Булган икән бер малай,
Ул еш кына елаган...
Алай ук еш еларга
Сәбәбе дә булмаган,
Ул барыбер елаган.

Аптырагач апасы,
Ул елакның апасы,
Ул малайның апасы —
Кызык рәсем ясаган.

Шул рәсемне
Малайга
Күрсәтә генә икән!
Малай туктап елаудан,
Кул чабып көлә икән!
Бот чабып көлә икән!
Баш кашып көлә икән!
Эч кашып көлә икән!

Шундый рәсем миңа кирәк,
Кем ясый белә икән?!

АЛЫПЛАР

I

Үскән ике бертуган —
Әкияттәге шикелле!
Укыганнар мәктәптә,
Алмаганнар икеле...

Ай үсәсен көн үсеп,
Алар егет булганнар.
Көч сынарга кергәннәр
Якындагы урманга...
Алдырырмы — энесе,
Җиңәр микән абыйсы?
Алып батыр һәркайсы,
Дөрес инде анысы!

II

Берсе шунда —
Бер тибеп,
Бер наратны аударган.
Икенчесе — бер тибеп,
Бер каенны сындырган.
Бер сугуда имән дә
Аударып караганнар.
Ә берьюлы икене? —
Булдыра алмаганнар!
Булдыра алмаганнар!

Сөенгәннәр шулай да.
Йөгергәннәр авылга.
Йөзләренә — горурлык,
Зурлык нуры кабынган!
Очып кайтып җиткәннәр,
Әтиләрен күргәннәр.
Урмандагы хәлне дә
Тиз үк сөйләп биргәннәр:
— Әйе, әти, валлаһи,
Шулай иттек! — дигәннәр.
— Алып булды улларың!
Үсеп җиттек! — дигәннәр.

III

Шуннан хәле аларның —
Болай булып чыккан, ди:
Әтиләре бер сугып —
Икесен дә еккан, ди.

Үсеп җиткән улларын
Кызык кына иткән ул.
...Агачларны кызганып,
Кызып кына киткән ул.

Үзе нык та сукмаган,
Таман гына иткән шул!
Әтисе дә аларның —
Алып булган икән шул!

СИМЕРДЕ

Минем дустым Симерде
Бик симерә башлады.
Әллә артык ашады,
Әллә ялгыш ашады?

Ашык-пошык ашады,
Шапыр-шупыр ашады.
Гел ашады-ашады,
Мыштыр-мыштыр ашады.
Кыштыр-кыштыр кимерде,
Шытыр-шытыр кимерде.
Кетер-кетер кимерде,
Кавын кебек симерде.

Инде тели тавыклар
Аны чукып карарга...
Кызыгалар көчекләр —
Аның эчен яларга...

Аны көтеп ач бүре —
Йөри икән урманда.
Бара күрмә, Симерде!
Бара күрмә син анда!

ЭЧТӘЛЕК

Ничә кабат чиртте? 3
Кая киткән 4
Укый белә эти дә 4
Җиде чебеш 5
Җил аягын күрмәдем 6
Әнем бар 6
Сөйләшә дә белми ул 7
Әле җәй безнең якта 8
Җылы яңгыр, Дамир һәм Гөлназ 8
Абыем белән апама 9
Күрегез 9
Хаталы шигырь 10
Иң зур кеше 10
Самолет 11
Шайтан килде кунакка 12
Әнкәй, эткәй һәм мин 13
Ха-ха! 13
Күршеләр 14
Кунак һәм без яки бер, ике, өч! 15
Ләхмәт, гәхмәт һәм рәхмәт 16
Галстуклы кәҗә 17
Очты-китте 17
Көрәк 18
Яз 19
Май килгән 20
Гөрләвеккә юл ачтык 21
Кемдер 21
Бәләкәй көймә 22
Яшен 23
Карлыганнар каралган 24
Бәхетле кыз Әнисә 24
Ятим малай 25
Чит мәче 25
Йә, әйтегез, белсәгез? 26
Барып чыктым чокырга 27
Кызык рәсем 28
Алыплар 29
Симерде 31